**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең**
**Иске Минзәләбаш авылы**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№2** **20.11.2021**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылы халык җыены карар итте:

1. I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Иске Минзәләбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга :

1) Иске Минзәләбаш торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Иске Минзәләбаш торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Иске Минзәләбаш торак пунктында Сабантуй бәйрәме үткәрү мәйданы территориясен төзекләндерү (территорияне коймаларын буяу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

4) Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

5) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ( аншлаг, коймалар яңартуга буяулар алу, биек үскән агачларны кисү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Җәйге чорда Иске Минзәләбаш торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

7) Иске Минзәләбаш торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

8) Иске Минзәләбаш торак пунктында чишмәләр территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу,буяу, конструкцияләрне ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү)

9) "Сарман" район гәҗитенә некрологлар бирү;

10) өстәл теннисы өчен инвентарь сатып алу

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов